**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

2015 ел, 17 сентябрь

№ 684

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 15 август, 388 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 15 август, 388 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 20 сентябрь, 492 нче; 2007 ел, 29 декабрь, 788 нче; 2008 ел, 17 ноябрь, 818 нче; 2009 ел, 22 июнь, 418 нче; 2010 ел, 1 апрель, 217 нче; 2010 ел, 6 декабрь, 1003 нче; 2010 ел, 10 декабрь, 1041 нче; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 13 декабрь, 1013 нче; 2012 ел, 2 июль, 576 нчы; 2012 ел, 17 сентябрь, 774 нче; 2013 ел, 22 май, 341 нче; 2013 ел, 22 август, 592 нче; 2013 ел, 26 октябрь, 799 нчы; 2013 ел, 19 ноябрь, 896 нчы; 2014 ел, 18 апрель, 253 нче; 2014 ел, 31 май, 372 нче; 2014 ел, 16 сентябрь, 665 нче; 2014 ел, 24 ноябрь, 902 нче; 2014 ел, 12 декабрь, 983 нче, 2015 ел, 11 июнь, 433 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның икенче абзацында «211», «1039,3» саннарын тиешле рәвештә «204», «1005,3» саннарына алмаштырырга, «алардан 204 берәмлек сандагысы Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финансланган 1005,3 мең сум вазыйфаи хезмәт хаклары буенча айлык эш хакы фонды белән» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына:

законнар нигезендә бу карарның 1 пунктын гамәлгә ашыруны, шул исәптән бу карар нигезендә штат санын киметү нәтиҗәсендә эштән азат ителгән дәүләт граждан хезмәткәрләренә гарантияләр һәм компенсацияләр бирүне тәэмин итә торган оештыру карарлары кабул итәргә;

2015 елның 31 декабренә кадәр Россия Федерациясе Социаль иминиятләү фондының территориаль органына Татарстан Республикасында яшәүче инвалидларны тернәкләндерүнең техник чаралары, протез-ортопедия эшләнмәләрен төзәтү һәм эшләүне дә кертеп, һәм шифаханә-курорт дәвалануына юлламалар белән тәэмин итү буенча эшне оештыру өчен кирәкле документларын һәм белешмәләрне тапшыруны тәэмин итәргә.

3. Бу карарның 1 пункты 2016 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\684.docx